КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 октябрь г.Казань № 1280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 11 июнь, 431 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 28 август, 755 нче, 2022 ел, 06 апрель, 318 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибенә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Әлеге Тәртип хезмәткәрләрнең, һөнәри берлекләрнең, аларның берләшмәләренең, вәкиллекле органнарның, бәхетсезлек очракларын тикшерү комиссияләренең вәкаләтле башка хезмәткәрләренең, шулай ук эш бирүчеләрнең,

аларның берләшмәләренең, иминиятчеләренең, башкарма хакимият органнарының, хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешмаларның турыдан-туры Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба - Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы) бирелгән гаризасы (алга таба - гариза) буенча «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты нигезендә экспертиза уздыруга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфатын бәяләү өчен хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын (алга таба - экспертиза) уздыру өчен түләү күләмен билгеләү максатларында эшләнде.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин